| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

21.07.2023　　　　　　　　　　№ 1091-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 октябрендәге 1282-п номерлы карары белән расланган, өстәмә социаль ярдәмгә мохтаж, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Укучылар өчен бушлай кайнар туклану оешмасы буларак, социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын бушлай тукландыруны тәэмин итү турында» 2019 елның 22 октябрендәге 1282-п номерлы карары белән расланган өстәмә социаль ярдәмгә мохтаж, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1-3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә башлангыч гомуми белем алучы балалар, күп балалы гаиләләрдән 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче 5 - 11 сыйныф укучылары, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга, шулай ук өйдә белем алучы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусына ия инвалид балалар өчен бушлай туклану продуктлары җыелмасын бирү яисә аны алмаштыру, акчалата компенсация белән тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен билгели.

2. 1 - 4 сыйныф укучылары өчен кайнар туклану Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән түләүсез оештырыла.

18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүче, 5 - 11 сыйныфта белем алучы, күп балалы гаиләләрдән булган укучылар өчен кайнар туклану

бушлай оештырыла һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән уку чорында бер укучыга кайнар иртәнге һәм төшке аш рәвешендә бирелә. Туклану бәясе Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.

3. Өйдә белем алучы, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусына ия инвалид балалар өчен, туклану продуктларын җыю яисә аның акчалата компенсациясе аена бер тапкыр, айның , уку көннәре саныннан, 20-нче числосыннан да соңга калмыйча, бирелә. Азык-төлек җыелмасының бәясе Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.».

**1.2.** Нигезләмәгә 3 нче кушымтаны яңа редакциядә әлеге карарга кушымта нигезендә бәян итәргә.

**2.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 21 июлендәге 1091 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 октябрендәге 1282-п номерлы карары белән расланган, өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ, Саба муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәгә 3 номерлы кушымта

Өйдә белем алучы, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусына ия инвалид балалар өчен азык-төлек җыелмасы рәвешендә туклану бирүгә ата-ананың (опекунның, тәрбия итүченең) гаризасы (ризалыгы) формасы.

Директорга
______________________________
Гомуми белем бирү оешмасының исеме
________________________________________
____________________/ җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
Кемнән______________________________
Атасының йә анасының (опекунның, тәрбия итүченең) фамилиясе
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
______________________________
______________________________
______________________________
гариза (ризалык).

Уку көннәрендә минем улыма ___________________________________
____________________________________________________________,
Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (туу датасы)

өйдә белем алучы ___ сыйныф укучысына
____________________________________________________________
(азык-төлек җыелмасы рәвешендә туклану яисә акчалата компенсация дип күрсәтелә)

бирүегезне сорыйм.

Дата_____________________ Имза_____________________